Татарстан РеспубликасыТүбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге составына керүче Кушай торак пунктында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елның 18 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлегенең Кушай торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Кашаево торак пункты, Шәңгәлче авыл җирлеге территориясе өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән гражданнарның үзара салымын, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан тыш, хәрби хезмәткә контракт төзегән һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның тормыш иптәше, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм катнашучыларның тол хатыннарыннан, белем алуның көндезге формасында белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның хатыннарыннан 1000 сум күләмендә кертергә; күрсәтелгән сумманың 50% күләмендә пенсионерлар һәм 80 яшьтән өлкәнрәк булган пенсионерлар.
2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:

– су скважинасына тирән насос сатып алу;
– Юлны ремонтлау (шул исәптән инертлы материаллар сатып алу, илтеп җиткерү, тигезләү һ.б.) - (Үзәк урам буенча Кашай авыллары;
– Зиратның коймасы.

Шәңгәлче авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Сәлимов

«Совет Шингальчинского сельского поселения Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан»
ИНН 1630003235
ОГРН 1041619007715